Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы
Колшәрип авылы башкарма комитеты

КАРАРЫ

21 октябрь 2022 ел №14

Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авылы башкарма комитетының 2017 елның 29 декабрендәге 10 номерлы «Әлмәт муниципаль районының Колшәрип авыл җирлеге кешеләр күпләп була торган торак секторда һәм объектларда янгын-профилактика эшен оештыру турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Янгын куркынычсызлыгы турында»1994 елның 18 ноябрендәге 719 номерлы карары нигезендә

Колшәрип авылы башкарма комитеты
КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Колшәрип авылы башкарма комитетының 2017 елның 29 декабрендәге 10 номерлы «Әлмәт муниципаль районының Колшәрип авыл җирлеге кешеләр күпләп була торган торак секторда һәм объектларда янгын-профилактика эшен оештыру турында»гы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

карарга 1 нче кушымтада:

I бүлекнең 3 пункты тугызынчы абзацында «Янгынга каршы пропаганда - җәмгыятькә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү проблемалары һәм юллары турында максатчан мәгълүмат бирү,» сүзләрен «Янгынга каршы пропаганда - җәмгыятькә янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү юллары турында хәбәр итү,» сүзләренә, «җайланма» сүзен «уздыру» сүзенә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Колшәрип авылы, Тукай урамы, 50 нче йорт территориясендә урнашкан махсус стендларда игълан итәргә, шулай ук «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы» (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәре сайтында урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылганнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырым.

Колшәрип авылы башкарма
комитеты җитәкчесе А.Ф. Кәшәфетдинов